**4 сыйныф өчен дәрестән тыш эшчәнлеккә аннотация**

“Кызыклы грамматика” дәрестән тыш эшчәнлек Россия Федерациясендәге һәм Татарстан Республикасындагы мәгарифкә кагылышлы хокукый-норматив актларга һәм федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп төзелде:

- Россия Федерациясенең "Мәгариф турында"гы Законы (Федеральный закон от 29.12.2012 273-ФЗ "Об образовании в Российской Федерации").

- Татарстан Республикасының "Мәгариф турында"гы Законы (Закон Республики Татарстан "Об образовании" № 68-ЗРТ от 22 июля 2013 года, статья 8).

- Россия Федерациясенең "Россия Федерациясе халыктелләре турында"гы 126-ФЗ нчы номерлы Законы (24.07.1998).

-Зур Мәшләк урта гомуми белем бирү мәктәбенең төп гомуми белем бирү программасы (2018 елның 16 августында №120 номерлы боерык белән расланган)
-Зур Мәшләк урта гомуми белем бирү мәктәбенең 2020-2021 уку елы өчен еллык календарь графигы 20.08.2020 елның № 99 о/д номерлы боерык белән расланган.

“Кызыклы грамматика” дәрестән тыш эшчәнлек укучыларны кызыксындыра торган материалларны үз эченә алды. Дәрестән тыш эшчәнлек кызыклы, мавыктыргыч булсын өчен уен, ярыш , сорау- җавап формалары кулланыла. Дәрес материаллары белән бәйләнешле булган өстәмә материаллар да үтәлә. Кызыклы, мавыктыргыч уеннар, фонетик күнегүләр авазларны дөрес әйтүгә этәргеч булып тора. Табышмаклар, башваткычлар, шарадалар һ.б. балаларның фикерләү, уйлау, хәтер сәләтен, игътибарлылыгын, кызыксынуын арттыра, сәләтләрен ачыкларга ярдәм итә. Тизәйткечләр балаларның ишетү сәләтен үстерә. Алар авазларны дөрес әйтергә, аваз куелышы, дикция өстендә эшләргә ярдәм итә. Ребуслар, кроссвордлар сүзләрнең дөрес язылышын үзләштерүдә отышлы.

**Максат һәм бурычлары:**

Гамәли максат: телне аралашу чарасы буларак үзләштерү өчен, укучыларга гаилә-көнкүрешкә, уку хезмәтенә бәйле ситуацияләре кысаларында белем бирү, күнекмәләр формалаштыру.

Гомуми белем бирү максаты: акыл эшчәнлеген активлаштыру, логик фикерләү сәләтен үстерү, сөйләм культурасын үстерү.

Тәрбияви максат: балаларның рухи дөньяларын баету, татар халкының мәдәнияте, сәнгате белән таныштыру,

төрле милләт вәкилләре арасында дуслык һәм хөрмәт хисе тәрбияләү.
Бурычлар :

1)Өйрәнелгән материалга нигезләнгән татар сөйләмен укытучыдан яки башка укучылардан ишетеп аңлау;

2)диалогик, монологик сөйләм күнекмәләрен формалаштыру;

3)текстларны сәнгатьле итеп, аңлап укый белү күнекмәләрен булдыру;

4)татар телендәге сөйләмне фонетик, лексик, грамматик яктан дөрес төзергә күнектерү.